**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“23” ноябрь 2019 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә торак пунктында этаплы халык җыены: 16 нчы ноябрь 19.00 сәг. һәм 23 ноябрь 19.00 сәг. лэрдә

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылы территориясендә 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

Түбән Бәрәскә авыл территориясен чистарту һәм төзекләндерү, агачларны кистерү һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү; басманы төзекләндерү, төзелеш кирәк-ярагын алу һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү; зиаратны төзекләндерү һәм карап тору өчен чыгымнар тоту;паркны төзекләндерү һәм карап тоту, парк эйләнәсен чистартып тоту, хезмәтләр өчен түләү,транспорт хезмәтләре өчен түләү, балалар мәйданчыгы өчен инвентарь алу һәм урнаштыру өчен чыгымнар тоту; урам утларын карап тоту, лампочкалар алу өчен чыгымнар тоту.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Түбән Бәрәскә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы Фатыйхова А.В.

Совет Нижнеберескинского сельского Поселения